Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге башкарма комитеты карары

2014 елның 12 апреле 29№

Җәмәгать тыңлауларны үткәрү урынында территорияне (бинаны) тутыруның чик нормаларын билгеләү турында.

2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 54-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасында митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар җыелышларын уздыруга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм җәмәгать тыңлаулары чараларында катнашучы гражданнарның, ачык чаралар үткәрү өчен файдаланыла торган объект һәм биналарның иминлеген тәэмин итү, шулай ук җәмәгать тыңлаулары чараларында катнашмаучы затларның хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларны булдырмау максатларында карар бирәм:

1. Юхмачы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында хәбәрнамә бирелгәндә чара үткәрү урынында территориянең( бина) тулыландырылуының түбәндәге нормаларын билгеләргә:

   - стационар тамашачы урыны белән җиһазландырылган бинаның иң чик тыгызлыгы - 200 стационар тамашачы урыны, Юхмачы авылы.

   - стационар тамашачы урыны белән җиһазланмаган бинаның иң чик тутырылышы җәмәгать тыңлаулары чарасы үткәрелгән урында 1 квадрат метрга бер кешедән артмый, яки бинаның (корылманың) техник паспорты нигезендә,

   - тротуар, административ биналар янындагы мәйдан һәм мәдәни-күңел ачу учреждениеләрендә - 1 квадрат метрга 3 кешедән артмый.

2. Әлеге карарны Юхмачы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Ф.А.Сәлахов